**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**ШАРШАДИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ШАРШАДЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

10.04.2020 Шаршады авылы № 8

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Шаршады авыл җирлеге территориясендә янгынга каршы махсус режим кертү турында

«Татарстан республикасы территориясендә аерым янгынга каршы режим билгеләү турында» 2020 елның 01 апрелендәге 242 номерлы Татарстан республикасы министрлар кабинеты карарын үтәү максатында, «Янгын куркынычсызлыгы турында» 1994 елның 21 декабрендәге 69-ФЗ номерлы Федераль законның 30 статьясы һәм «Янгын куркынычсызлыгы турында» 1993 елның 18 маендагы 1866-XII номерлы Татарстан Республикасы Законының 25 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы нигезендә, ачык территорияләрдә ландшафт янгыннары артуга бәйле рәвештә, Шаршады авыл җирлеге территориясендә язгы-җәйге чорда янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Шаршады авыл җирлеге башкарма комитеты

## КАРАР БИРӘ:

1. Билгеләргә:

- 2020 елның 10 апреленнән 17 майга кадәр Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Шаршады авыл җирлеге территориясендә янгынга каршы махсус режим кертелә дип.

2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Шаршады авыл җирлеге территориясендә янгынга каршы махсус режим чараларының кушымтада бирелгән планын расларга.

3. 2020 елның 10 апреленнән 17 маена кадәр чорда тыярга:

- коры үлән һәм чүп-чар яндыруны;
- Әгерҗе муниципаль районы Шаршады авыл җирлегенең торак пунктлары территорияләрендә хәвефнең 1-3 класслы пиротехник эшләнмәләр куллануны, урман янгыннарына, бакчачылык һәм яшелчәчелек ширкәтләренә, балалар ялы оешмаларына һәм аларны савыктыру оешмаларына, урман кишәрлекләре белән чиктәш экомика объектларына, савыктыру оешмаларына, шулай ук урман-парк

зоналарында, торфлы участокларында һәм ачык территорияләрдә урман массивлары белән чиктәш ачык территорияләрдә ачык утта (учакларда, мангаларда) азык әзерләүне.

4. 2020 елның 10 апреленнән 17 майга кадәр чорга Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Шаршады авыл җирлегенең милек рәвешләренә бәйсез рәвештә муниципаль учреждениеләр (оешмалар, предприятиеләр) җитәкчеләренә тәкъдим итәргә:

4.1. үз территорияләрендә янгын куркынычсызлыгы буенча өстәмә таләпләр билгеле торган, шулай ук янгыннарны профилактикалау чараларын үткәрүне һәм аларны уңышлы юкка чыгару өчен шартлар тудыруны күздә тота торган локаль актлар кабул итәргә (су запасларын, янгынны сүндерү чараларын булдыру, чүп-чарны җыештыру, коры үсемлекләрне бетерү һ.б.лар).

4.2. тормыш тәэмин итү объектларында янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен үтәүне контрольдә тотуны көчәйтергә, объектларда җитәкче составның тәүлек буе кизү торуын оештырырга. Янгынга каршы махсус режим гамәлдә булган чорда янгын куркынычы эшләре башкаруны чикләргә.

4.3. ведомство буйсынуындагы объектларның территорияләрен коры үләннән һәм чүп-чардан чистарту чараларын күрергә, янгынга каршы тышкы су белән тәэмин итүнең балансында булган эш сәләтен тикшерергә, янгынга каршы махсус режим гамәлдә булган чорда янгын куркынычы эшләрен башкаруны чикләргә;

4.4. янгын чыккан очракта янгын куркынычсызлыгы чаралары һәм эшгамәлләр турында оешмалар хезмәткәрләре, авыл халкы арасында аңлату эшләре алып барырга.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Әгерҗе авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Әгерҗе муниципаль районы рәсми сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә (http://agryz.tatarstan.ru).

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземә алам.

Җитәкчесе В.Х.Бәһаветдинов

Исполнительный комитет Шаршадинского сельского поселения
Шаршады авыл җирлеге башкарма комитеты
ОГРН 1061674014753
ИНН 1601006030

Расланган
Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы
Шаршады авыл җирлеге
башкарма комитетының
10.04.2020ел, № 8
карары белән

**Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Шаршады авыл җирлеге территориясендә янгынга каршы махсус режим чаралары-ның ПЛАНЫ**

| № | Төп чаралар | Башкару сроклары | Башкаручылар |
|---|---|---|---|
| 1. | Гадәттән тыш хәлнең (һәлакәтнең) килеп чыгышы турында җитәкче со-ставка һәм формированиеләргә хәбәр итүне оештырырга | 2020 елның ап-реле | Шаршады авыл җирлеге баш-карма комитеты җитәкчесе, ян-гын куркынычсызлыгы өчен җаваплы зат |
| 2. | Гадәттән тыш хәлләр (һәлакәт) килеп чыгу ихтималы турында халыкка хәбәр итүне оештырырга | 2020 елның ап-реле | Шаршады авыл җирлеге баш-карма комитеты җитәкчесе, ян-гын куркынычсызлыгы өчен җаваплы зат |
| 3. | Предприятиеләр, оешмалар, яшелчә бакчалары территорияләрендә учаклар ягуны һәм чүп-чар яндыруны тыярга | 2020 елның 10 апреленнән 17 маена кадәрге чорда | Шаршады авыл җирлеге баш-карма комитеты җитәкчесе, ян-гын куркынычсызлыгы өчен җаваплы зат |
| 4. | Янгын куркынычсызлыгы чаралары һәм янгын вакытында гамәлләр ту-рында гражданнар белән аңлату эшләре алып баруны оештырырга | 2020 елның 10 апреленнән 17 маена кадәрге чорда | Шаршады авыл җирлеге баш-карма комитеты җитәкчесе, ян-гын куркынычсызлыгы өчен җаваплы зат |
| 5. | Муниципаль берәмлек территори-ясендә оешмалар җитәкчеләренә:<br>- янгынга каршы махсус режим бил-геләү турында оештыру оешмалары хезмәткәрләренә мәгълүмат бирергә;<br>- оешма территориясендә яисә оешмадан читтә янгын куркынычы эшләрен башкару өчен җәлеп ителә торган эшләр белән янгын курк-ынычсызлыгы буенча планнан тыш ин-структаж үткәрергә;<br>- аеруча куркыныч участокларда ян-гын торышын контрольдә тотуны ое-штырырга | 2020 елның 10 апреленнән 17 маена кадәрге чорда | Милек рәвешләренә бәйсез рәвештә, муниципаль учрежде-ниеләр, оешмалар (предприяти-еләр, учреждениеләр) җитәк-челәре |
| 6. | Янгынга каршы су белән тәэмин итү чыганакларының, биналарга, торак йортларга юлларның әзерлеген тик-шерергә | 2020 елның 10 апреле | Шаршады авыл җирлеге баш-карма комитеты җитәкчесе, ян-гын куркынычсызлыгы өчен җаваплы зат |
| 7. | Табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәл вакытында халыкка | 2020 елның 10 апреле | Шаршады авыл җирлеге баш-карма комитеты җитәкчесе, ян- |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | хәбәр итү системасын тикшерергә | | гын куркынычсызлыгы өчен җаваплы зат |
| 8. | Җирлекнең муниципаль берәмлеге территориясендә урнашкан вәзгыять буенча Әгерҗе муниципаль районы ЕДДС белән тыгыз хезмәттәшлекне оештырырга | даими | Шаршады авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе, янгын куркынычсызлыгы өчен җаваплы зат |
| 9. | 01, 112 телефоннары буенча профессиональ янгын сүндерүчеләрне чакыру | Ачыкланганда кичекмәстән | Янгынны ачыклаучы һәм Шаршады авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе, янгын куркынычсызлыгы өчен җаваплы зат (чакыруны раслый) |
| 10. | Халыкка һәм район хакимияте җитәкчелегенә янгын чыгу турында (телефоннар аша, җәяүле тәртиптә һәм автотранспортта) хәбәр итү | Ачыкланганда кичекмәстән | Шаршады авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе, янгын куркынычсызлыгы өчен җаваплы зат |
| 11. | Янгын чыгу урынына, янгын сүндерү белән җитәкчелек итү өчен, профессиональ янгын сүндерүчеләр килгәнче килү | Ачыкланганда кичекмәстән | Шаршады авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе, янгын куркынычсызлыгы өчен җаваплы зат |
| 12. | Куркынычсыз урынга кешеләрне һәм мөлкәтне янгын чыганагыннан эвакуацияләүне оештыру | Янгын учагы зонасына килеп җиткәндә | Шаршады авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе, янгын куркынычсызлыгы өчен җаваплы зат |
| 13. | Һөнәри янгын сүндерүчеләр килеп җиткәч, аларның өлкәннәренә килеп туган хәл һәм күрелгән чаралар турында хәбәр итәргә | Профессиональ янгын сүндерүчеләр килеп җиткәндә | Шаршады авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе, янгын куркынычсызлыгы өчен җаваплы зат һәм профессиональ янгын сүндерүчеләр бүлекчәсен каршы алучы |
| 14. | Район башлыгына янгын сүндерү барышы турында доклад | Сәгать саен | Шаршады авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе |
| 15. | Район башлыгына янгынны бетерү турында доклад | Янгынны сүндергәннән соң | Шаршады авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе |
| 16. | Хәлне анализлау һәм алдан килгән зыянны һәм зыян күрүчеләрнең санын билгеләү | Янгынны сүндергәннән соң | Шаршады авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе |
| 17. | Зыян күргән халыкның беренче чиратта яшәешен тәэмин итүне оештыру | Янгынны сүндергәннән соң | Шаршады авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе |